**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Петровка торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**2025 елның 24 ноябре** **№2**

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Петровка торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровка Кәүҗияк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшькә җиткәннәр), көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, һәм вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылардан кала, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ-82 тракторын тоту: дизель ягулыгы, дизмай, зап часть сатып алу);

2) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау; урамнарны яктырту җайланмаларын урнаштыру (Петровка торак пунктында энергияне саклый торган лампалар сатып алу һәм урнаштыру, яктырткычларны һәм урамнарны яктырту лампаларын алыштыру).

3. Җыен нәтиҗәләрен Кәүҗияк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы ___________ Ф. Ә. Хөснетдинов